СОВЕТ СТЕПНОШЕНТАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АЛЕКСЕЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ КЫР ШОНТАЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

с.Степная Шентала

**РЕШЕНИЕ** 30.07.2024

**КАРАР** № 70

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Советының 16.11.2018 ел, №78 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» (18.11.2019 №108 дәге үзгәрешләр белән) карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып, физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» 2014 елның 30 октябрендәге 82-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Кыр Шонталы авыл җирлеге Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Кыр Шонталы авыл җирлеге Советының 16.11.2018 ел, №78 «Физик затлар мөлкәтенә салым турында»(18.11.2019 №108 дәге үзгәрешләр белән) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) 2025-2027 еллар чорына карата 1,2%:

гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле һәм сәүдә үзәкләренең (комплексларның) һәм алардагы Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацы нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән биналарның.»

2.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru)бастырып чыгарырга, шулай ук Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

**Кыр Шонталы авыл җирлеге Башлыгы, Совет Рәисе** **Г.Н.Кыямова**